ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.08.2022 Олы Кайбыч ав. № 373

Хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Балаларда һәм яшьләрдә сәләтләрне һәм талантларны ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү системасының нәтиҗәлелеге» күрсәткечен бәяләүгә керүче белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын раслау турында

«2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указлары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Балаларда һәм яшьләрдә сәләтләрне һәм талантларны ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү системасының нәтиҗәлелеге» күрсәткечен бәяләүгә керүче белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын кушымтада каралганча расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы И.И. Хәмидуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы,
Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең
беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллина

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
«25» 08. 2022 №373
карарына кушымта

**Хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Балаларда һәм яшьләрдә сәләтләрне һәм талантларны ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү системасының нәтиҗәлелеге» күрсәткечен бәяләүгә керүче белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Регламентны җайга салу предметы.

Әлеге хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Балаларда һәм яшьләрдә сәләтләрне һәм талантларны ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү системасының нәтиҗәлелеге» күрсәткечен бәяләүгә керүче белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары, «Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 елның 31 декабрендәге 920 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы «Контроль» модуленең эшләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 18 апрелендәге 361 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнгән һәм хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Балаларда һәм яшьләрдә сәләтләрне һәм талантларны ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү системасының нәтиҗәлелеге» күрсәткечен бәяләүгә керүче белешмәләрне җыю һәм мониторинглау өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматларны җыю тәртибен билгели (алга таба – декомпозицияләнгән күрсәткеч):

2015 елдан хисап елы тәмамланганчы талантлары һәм сәләтләре ачыкланган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр өлеше, процентлар;

хисап елында сәләтләрен м күрсәткән һәтөрле формаларда дәүләт ярдәме алган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр өлеше, процентлар.

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ (алга таба - мәгариф бүлеге) Кайбыч муниципаль районындагы декомпозицияләнгән күрсәткечләрне жыю һәм мониторинглау өчен җаваплылык үзәге булып тора.

Белешмә мәгълүмат.

Әлеге регламент максатлары өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану методикаларын раслау турында» 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары белән кертелгән, Россия Федерациясе субъекты дәрәҗәсендә «балаларда һәм яшьләрдә сәләтләрне һәм талантларны ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү системасының нәтиҗәлелеген» бәяләүгә кирә торган күрсәткечләрне исәпләү методикасында билгеләнгән терминнар кулланыла.

## 2. Исәпләү стандарты, жыю тәртибе һәм мәгълүматлар бирү

Lекомпозицияләнгән күрсәткечләрне исәпләп чыгару өчен түбәндәге мәгълүматлар кулланыла:

7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләрнең гомуми саны, кеше;

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән, һәм (яисә) теркәлгән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре булган, һәм (яисә) фәнни халыкара яисә бөтенроссия басмаларында мәкаләләр авторлары булып торучы, шул исәптән халыкара мәгълүмат базаларында индексацияләнә торган басмаларда (Web of Science, Scopus h.б.) җиңүче булган һәм (яисә) теркәлгән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре булган исемлеккә кертелгән олимпиадалар һәм башка конкурс чаралары призерларына әверелгән балалар һәм яшьләр саны (алга таба - 2015 елдан башлап сәләтләре һәм талантлары ачыкланган 7 яшьтән алып 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны);

хисап елында сәләтләрен күрсәткән һәм төрле формаларда дәүләт ярдәме алган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны, кеше.

Мәгариф бүлегенең җаваплы хезмәткәре югарыда күрсәтелгән ярдәмче күрсәткечләр буенча хисап чорында белешмәләр жыюны гамәлгә ашыра:

7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балаларның һәм яшьләрнең гомуми саны буенча - «Ачык Татарстан» системасы мәгълүматлары нигезендә;

2015 елдан башлап сәләтләр һәм талантлар ачыкланган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны буенча- әлеге муниципаль районда (шәһәр округында) урнашкан гомуми белем бирү оешмаларыннан балалар турында мәгълүматлар базасын жыю гамәлгә ашырыла.

Мәгариф бүлеге җаваплы хезмәткәре электрон рәвештә мәгълүматлар җыю формасын җибәрә, мәгариф оешмасы вәкилләре анда укучыларның казанышлары

турында түбәндәге белешмәләрне кертәләр:

1. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән конкурс чараларында призлы урыннар;

2. интеллектуаль эшчәнлекнең теркәлгән нәтиҗәләре;

3. фәнни халыкара яисә бөтенроссия басмаларында, шул исәптән халыкара мәгълүмат базаларында индексацияләнә торган басмаларда мәкаләләр бастырып чыгару (Web of Science, Scopus һ.б.).

Атаклы сәләтләрен күрсәткән балалар турында мәгълүматлар базасы бөтен муниципаль район (шәһәр округы) буенча җыелма формада яшь кешеләрне һәм аларның казанышларын исәпкә алу өчен, шулай ук алынган ярдәм чараларын теркәү өчен электрон рәвештә саклана.

7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны буенча, үзләренең сәләтләрен таныткан һәм хисап елында төрле формаларда дәүләт ярдәме алган балалар һәм яшьләр саны буенча - мәгариф бүлегенең җаваплы хезмәткәре узган елның 11 нче сыйныф укучыларында танылган сәләтләрен күрсәткән балалар турында мәгълүматлар базасына кертелгән дәүләт ярдәме чаралары турында мәгълүмат сорату юлы белән мәгълүматлар җыя. Мониторингка керергә тиешле дәүләт ярдәме чаралары 2023 елдан башлап, ел саен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

Мәгариф бүлегенең җаваплы хезмәткәре Кайбыч муниципаль районы буенча җыелма мәгълүматны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Казан талантлар университеты 2.0» автоном коммерцияле булмаган оешмасы адресына mon.sbor@tatar.ru һәм info@utalents.ru электрон почтасы адресына мәгълүмат күчермәсе белән Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасын аша рәсми хат җибәрә. 2023 елдан сәләтле балалар турында мәгълүматлар базасын җыю «Казан талантлар университеты 2.0» автоном коммерцияле булмаган оешмасы порталы аша гамәлгә ашырылачак.

## 3. Мәгълүматларның составы, бирелү вакыты һәм тәэмин итүчеләре

3.1. Хисап елында төрле рәвештә сәләтләрен күрсәткән һәм төрле формаларда дәүләт ярдәме алган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны

3.2.

| т/б № | Оешма исеме | Үлчәү берәм леге (кеше) | Мәгълүмат бирү срогы хисап аеннан соң килүче айның 1 числосына кадәр квартал саен | Хисап елында төрле рәвештә сәләтләрен күрсәткән һәм төрле формаларда дәүләт ярдәме алган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

3.3. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән, һәм (яисә) теркәлгән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре булган, һәм (яисә) фәнни халыкара яисә бөтенроссия басмаларында мәкаләләр авторлары булып торучы, шул исәптән халыкара мәгълүмат базаларында индексацияләнә торган басмаларда (Web of Science, Scopus һ.б.) җиңүче булган һәм (яисә) теркәлгән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре булган исемлеккә кертелгән олимпиадалар һәм башка конкурс чаралары призерларына әверелгән балалар һәм яшьләр саны

| т/б № | Оешма исеме | Үлчәү берәм леге (кеше) | Мәгълүмат бирү срогы хисап аеннан соң килүче айның 1 числосына кадәр квартал саен | Хисап елында 2015 елдан башлап сәләтләре һәм талантлары ачыкланган 7 яшьтән алып 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |